„НОРЛАТНЕФТЬ“ НГДУсы ЮБИЛЕЕНА

# „Кара алтын“— ил байлыгы



## 5. Эшче кадрлар хәзерлибез

«Норлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенең укыту-курс комбинатында квалификацион имтиханнар билгеләнгән вакытта башланды.

Өч ай эчендә 50 дән артык кеше производстводан аерылмыйча сыек һәм газ ягулыгында эшләүче котельня җайланмалары операторлары хәзерләү группаларында өйрәнү үттеләр. Һәм менә укуга һәм производство практикасына йомгак ясар вакыт җитте.

Имтихан билетлары кебек, диләр. Әмма укуга һәм практик күнекмәләрне үзләштерүгә чынлап торып бирелгән кешеләргә теләсә нинди билет соравы да куркыныч түгел. Шундыйларның берсе пар һәм су белән тәэмин итү цехында эшләүче—Владимир Кузнецов. Ул үзәктән кудыру насосын карау һәм ремонтлау ысуллары турында, мичкәдә су күләме азайганданиләр эшләргә кирәклеген, су тигезлеген күрсәтү приборларын өрдерү тәртибе турында сөйләде. Экономика буенча да җавап тотты. Аңа эш урыннарын аттестацияләү һәм зарарлы эш шартлары өчен өстәмә түләү ничек билгеләнүе турында да сөйләргә туры килде.

В. Кузнецов төп һәм өстәмә сорауларга да тулы һәм төгәл җавап бирә. Бу аңлашыла да, ул —җитди работник. 1986 елдан бирле котельня җайланмалары операторы булып эшли. Иң баштан өченче разряд буенча эшләде, аннары укып дүртенче разрядка ия булды. Ә хәзер бишенче разряд алу өчен тырыша. Квалификацион комиссия членнары —Лениногорск районының тау-техник инспекция инспекторы Г. К. Нуруллин, пар һәм су белән тәэмин итү цехы начальнигы А. И. Сергеев аның җавапларыннан канәгать калдылар.

Укыту-курс комбинатында яңа эшчеләр хәзерләгәндә, икенче профессиягә өйрәткәндә, эшчеләрнең квалификацияләрен күтәргәндә тулы хуҗалык исәбе, үзфинанслау һәм чыгымнарны каплау шартларында производствоны оештыру һәм экономика мәсьәләләрен өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Ул эштән аерылмыйча нефть промышленносте карарларын профессиональ һәм экономик өйрәтү турындагы 1988 елда Министрлык тарафыннан расланган, нефть һәм газ промышленносте эшчеләре профсоюзы Үзәк Комитеты белән килешенгән положение буенча тулысынча алып барыла.

УККда махсус җиһазландырылган экономика кабинеты бар. Имтиханнар дәвам итә. Сергей Смирнов һәм Любовь Казачкова профессиональ цикл дәресләрен дә яхшы белүләрен күрсәттеләр.

Югарыда аталган цех работниклары белән бергә ул көнне идарәнең башка нефть һәм газ чыгаручы беренче һәм икенче цехлары, юл участогы, районның башка предприятиеләре һәм оешмалары эшчеләре дә имтихан тоттылар.

Агымдагы елда укыту-курс комбинатында нефть чыгару буенча операторлар, скважиналарга җир асты һәм капиталь ремонт үткәрү цехы бораулаучы ярдәмчеләре һәм операторлары, химик су белән чистарту аппаратчылары, күтәртү тракторлары машинистлары һәм башка бик күп профессия кешеләре укыдылар. Аларның күпчелеге үзләренең квалификацион разрядларын күтәрделәр.

Эшчеләрнең профессиональ хәзерлекләрен арттыруны идарә администрациясе һәрвакыт күз угында тота. Аның белән бәйле мәсьәләләр укыту-методик совет утырышларында һәм техник киңәшмәсендә тикшерелә.

Күптән түгел предприятиенең хезмәт коллективы советы утырышында җитди сөйләшү булды. Кадрлар хәзерләү буенча эшнең барышы турында отчет тыңланды. Укыту-курс комбинатының бу юнәлештә әйбәт эшләве билгеләп үтелде. Аның эшен камилләштерү буенча теләкләр әйтелде.

УККда ел саен 150 дән артык работник хәзерлек, яңадан укытуны үтәләр һәм икенче профессия үзләштерәләр. 300 дән артык эшче үзләренең профессиональ квалификацияләрен күтәрәләр. Эшне кадрлар хәзерләү буенча план-задание һәр елны уңышлы үтәлә.

Шунысын да әйтми булмый. Укыту-курс комбинаты кирәкле укыту-материаль база, техник кабинетлар, полигон, заман таләпләренә җавап бирердәй җиһазлар, инструментлар, җайланмалар һәм күргәзмә әсбаплар белән тәэмин ителгән.

Монда производствога өйрәтүне 30 дан артык укытучы алып бара. Аларның бишесе штатлы, калганнары техник хәзерлек үткән предприятие җитәкчеләре һәм белгечләре. Кагыйдә буларак, инструкторлар итеп үз эшләрен яхшы белүче белгечләр һәм мастерлар билгеләнгән. Укытучылар укучыларга яңадан-яңа белемнәрне үзләштерергә булышуны үзләренең төп эшләре итеп саныйлар, ә инструкторлар ул белемнәрне практикада кулланырга ярдәм итәләр.

Алган белемне эштә куллану исә өйрәнгән материалга ышанырга мөмкинлек бирә, укучыларның иҗади фикерләүләрен стимуллаштыра. Болар барысы да ахыр чиктә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә дә чагыла, шулай ук алдагы эшкә кызыксынучанлыкны арттыра.

**В. БУРАЙКИН,**
«Норлатнефть» НГДУсының кадрлар бүлеге начальнигы, СССР Журналистлар союзы члены.



**Аркадий Иванович Емельяновның (рәсемдә) шоферлык стажы 35 елдан артык. Сәүдә базасы автогаражында эшләве дә 24 еллап исәпләнә. Гаҗәеп намуслы, сабыр һәм белемле шоферның коллективта абруе зур. Ерак рейсларга иң җаваплы йөкләр кайтарырга гадәттә Аркадий Ивановичны җибәрәләр һәм аның беркайчан да аны үтәмичә калганы юк. Тагын бер күркәм ягы бар Аркадий Ивановичның: ул яшьләр белән эшли белә. Яңа эш башлаучыларның күбесе беренче киңәшне Емельяновтан ала, аны үзенең остазы дип санаучылар коллективта байтак җыела.**

**Әнә шулай хөрмәтле эшче, сабыр остаз Аркадий Иванович. Шуның өстенә, аның үрнәк гаилә башлыгы икәнен дә, зур ихтирам белән телгә алалар коллективта.**

### САННАР һӘМ ФАКТЛАР

1913 елда татар телендә чыккан басмалар саны (дини характердагы әдәбиятны да кертеп) 340 исем тәшкил итте. Хәзер басмаларның саны 203 кә җитте. Уртача тираж 4,9 меңнән 13,7 мең данәгә кадәр җитте.

x x x

Өлкә партия оешмасы составында 46 милләт кешесе бар. Шуларның 47,4 проценты—руслар, 3,3 проценты—чувашлар.

## Җитди сөйләшү булды

Күптән түгел Норлат разведка бораулавы идарәсенең партия, профсоюз һәм хуҗалык активы конференциясе булып узды. Анда идарә начальнигы Ю. Г. Мөхәрмәтов һәм профсоюз комитеты председателе Г. Ш. Сөләйманов докладлар белән чыктылар. Отчет чорында, үзгәртеп кору, демократия һәм хәбәрдарлык процессын алга таба үстерә бару елында нефть эзләүчеләр коллективы шактый эш башкарды, план заданиеләрне һәм социалистик йөкләмәләрне үтәүдә күркәм уңышларга иреште.

НУРБ коллективы илебезнең социаль-экономик үсешен тизләтүгә үзләреннән лаеклы өлеш керттеләр.

Фән-техника казанышларын һәм прогрессив технологияне киң куллану 1989 елда тау токымнарын бораулау планын срогыннан алда, 24 декабрьгә үтәргә мөмкинлек бирде. Пландагы 186200 метр урынына 188132 метр тау токымы казылды.

Ел дәвамында иң югары күрсәткечләргә мастерлар М. Н. Хәсәншин, В. В. Фомин, М. Ф. Ананьев, В. А. Трифонов җитәкләгән бригадалар иреште.

Яңа экономик реформа шартларында рационализаторлык хәрәкәте эше яхшырды. Уйлап табучыларның 84 тәкъдиме нәтиҗәсендә 166200 сумлык экономия ясалды.

Ел дәвамында эшчеләр, инженер-техник работниклар арасында предприятиенең хуҗалык исәбенең икенче моделенә, үз-үзеңне аклауга һәм үзфинанслауга күчүе буенча экономик белемнәрне күтәрү дәресләре үткәрелде.

Конференция Норлат разведка бораулавы идарәсе администрациясенең, партркомның, профком һәм комсомол комитетының производство һәм идеология эшендә уңай яклар белән бергә кайбер җитешсезлекләр булуын билгеләп үтте.

Бригада һәм цехлар эшендә техник-экономик күрсәткечләрне яхшыртуда булган мөмкинлекләр тулысынча файдаланылмый. Бораулаганда өч очракта брак җибәрелгән. Скважиналар төзү цехы планын үтәмәде. Узган ел белән чагыштырганда, бер бораулау бригадасына уртача күрсәткеч 110 метрга кимеде. Бораулау һәм вышка монтажлау бригадалары тулысынча эш белән тәэмин ителмәделәр. Хезмәт дисциплинасын бозу очраклары да бетерелмәгән. Торак җитешми. Материалларны, запас частьләрне, ягулык-энергия ресурсларын экономияләү буенча эш тиешенчә куелмаган.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, барлык оештыру эшен хезмәт һәм технология дисциплинасын, фән, техника прогрессын тизләтүгә, эшнең сыйфатын һәм эффектлылыгын күтәрүгә, скважина төзелешенең үзкыйммәтен арзанайтуга, тулы хуҗалык исәбе шартларында материалларны, ягулык-энергетика ресурсларын экономияле куллануга юнәлдерергә кирәклеге күрсәтелде. Һәр алдынгы башлангычны, алдынгылар һәм новаторлар тәҗрибәсен производствога кертү, бораулау бригадалары һәм цех эшчеләре арасында планның барлык техник-экономик күрсәткечләрен үтәү буенча социалистик ярышны киңрәк җәелдерү, яңа экономик реформа шартларында 1990 елга кабул ителгән оештыру-техник чараларны үтәү зарурилыгына басым ясалды. Ел дәвамында бораулау бригадаларының һәрберсенең 19 мең метр тау токымы бораулап үтүенә, рационализаторлык эшчәнлеге белән киңрәк шөгыльләнү, барлык скважиналарны үзләштерү бригадаларын бригада подрядына һәм өзлексез эш графигына күчерү, эштә технологик һәм производство дисциплинасы белән бәйле булган тәртип бозулар аркасында авария һәм брак җибәрүне кисәтү проблемалары да күтәрелде.

1990 елда промышленность базасын һәм торак поселокны төзекләндерү буенча эшне дәвам итү, азык-төлек программасын үтәү максатыннан эшләнгән чараларга туры китереп, М. Җәлил исемендәге колхозга шефлык ярдәме күрсәтүне дәвам итәргә карар кылынды.

Доклад буенча фикер алышуда БПО эретеп ябыштыручысы Г. Г. Газизов, ЦОС мастеры Р. К. Сафин, ВМЦ начальнигы М. Б. Мәгъсумов, баш инженерның техника куркыныч с ы з л ы г ы буенча урынбасары И. М. Черкасов, «Теремок» балалар комбинаты мөдире З. Ф. Борзова, геофизиканың баш геологы Н. П. Маринин, «Норлатнефть» НГДУсы начальнигының капиталь төзелеш буенча урынбасары Х.Г. Ильясов, «Татнефть» берләшмәсенең генераль директоры урынбасары Р. Х. Фаткуллин иптәшләр катнаштылар.

Алар ирешелгән хезмәт уңышлары турында сөйләделәр, җитешсезлекләргә тукталдылар, үзләренең тәкъдимнәрен әйттеләр.

**И. ИСХАКОВ.**

